Республика Татарстан
СОВЕТ ВЕРХНЕСИМЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422055, Республика Татарстан,
с.Верхний Симет, ул. Советская, 32
тел. 45-0-19

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ СИМЕТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422055, Татарстан Республикасы,
Югары Симет авылы , Совет урамы, 32 йорт
тел. 45-0-19

e-mail: Bsim.sab@tatar.ru

23.09.2019 № 15

КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Югары Симет авыл җирлеге Советының
“Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Югары Симет авыл җирлеге Советы
Регламентын раслау турында” 25.12.2009 елгы №17а
карарына үзгәрешләр кертү турында.

ТР Саба районы прокуратурасының 10.09.2019 елгы №02-01-20-19 хатына, Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Уставына туры китереп, Югары Симет авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советының 25.12.2009 елгы №17а карары белән расланган Югары Симет авыл җирлеге Советы Регламентына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1 Регламентның 6 нчы бүлеген түбәндәге эчтәлекле 35 статья белән тулыландырырга:

“Статья 34.1:

1. Югары Симет авыл җирлеге башлыгы, район прокуроры, шулай ук Югары Симет авыл җирлеге Уставы, закончалык белән вәкаләтле вазыйфаи затлар, Советның ачык һәм ябык утырышларында катнашырга хокуклы.

2. Советның ачык утырышларында Югары Симет авыл җирлегендә яшәүчеләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

3. Совет тарафыннан аларның эшчәнлегенә караган сорауларны караганда, башкарма комитет эшчеләре ачык утырышларда катнашырга хокуклы.

4. Әгәр гомуми депутатларның күпчелеге тарафыннан хупланса, Совет җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының утырышта катнашуын таләп итәргә хокуклы.

Катнашу турында таләп, утырышка кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, Совет утырышына чакырылучы вазыйфаи затка утырышның көне, вакыты, урыны, утырышка куелган сораулар турында Совет рәисе тарафыннан хәбәр ителергә тиеш.

5. Утырышны ачар алдыннан, Совет рәисе Совет депутатлары булып тормаучы, утырышта катнашучы затлар турында игълан итә.

6. Утырышка чакырылган һәм катнашучы затлар Совет эшенә тыкшынырга хокуклы түгел. (чыгыш ясарга, белдерү эшләргә, хуплау яки ризасызлык белдерергә)

7. Совет карары нигезендә, чакырылганнарга әлеге Регламент кысаларында чыгыш ясау өчен сүз бирелергә мөмкин.”

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/ simet адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырырга.

9. Карар рәсми бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Югары Симет авыл җирлеге башлыгы: И.Р.Әхмәдуллин